| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.06.2023 Казан ш № 510

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен бирү (күрсәтү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 22 сентябрендәге 670 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен бирү (күрсәтү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен бирү (күрсәтү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 22 сентябрендәге 670 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 19.07.2016 №412, 08.06.2017 №348, 25.01.2018 №60, 07.05.2018

№ 348, 18.09.2018 №885, 02.07.2019 №509, 14.11.2019 №1016, 07.02.2020 №80, 01.09.2020 №605, 22.12.2020 №885, 02.06.2021 №385, 06.08.2021 №564, 01.10.2021 №709, 30.05.2022 №437, 07.11.2022 №988 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен бирү (күрсәтү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 29.06.2023 ел, №510 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен бирү (күрсәтү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 22 сентябрендәге 670 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен бирү (күрсәтү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2.4.1 пунктта:

икенче, өченче, дүртенче абзацларда «2.5» саннарын «2.6» саннары белән алыштырырга;

2.4.1 пунктның унынчы абзацында «10» саннарын «30» саннары белән алыштырырга;

2.7.1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«шәхси эшкуарлык эшчәнлеген (һөнәри керемгә салым түләүче буларак эшчәнлекне) гамәлгә ашыру, гариза бирүче яшәү урыны буенча яшәгән муниципаль берәмлек чикләреннән тыш шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару буенча социаль контрактлар кысаларында эшчәнлекне планлаштыру.»;

түбәндәге эчтәлектәге 2.7.2 пункт белән тулыландырырга:

«2.7.2. Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен бирү (күрсәтү) буенча хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар әлеге Регламентка 7 нче кушымтадагы форма буенча рәсмиләштерелә.»;

2.8.2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә , шул исәптән социаль контракт нигезендә, каралган бюджет ассигнованиеләренең булмавы (җитмәве);

сайлап куелган эшчәнлек төренең бизнес-планының ведомствоара комиссия тарафыннан билгеләнгән икътисадый нәтиҗәсезлеге (шәхси эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару чараларын гамәлгә ашыруга социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме билгеләнүне сорап мөрәҗәгать иткәндә);

«Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә гражданның яисә аның гаилә әгъзаларының җир кишәрлегенә милек хокукы яисә башка хокукы булмау (шәхси ярдәмче хуҗалыкны алып бару чараларын гамәлгә ашыруга социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме билгеләнүне сорап мөрәҗәгать иткәндә).»